**Казан шәһәре Думасының**
**2026 елның 26 февралендәге 9-6 номерлы карары**

**Казан шәһәре Думасының «“Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе” муниципаль казна учреждениесе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2025 елның 29 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм әлеге исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2010 елның 29 декабрендәге 24-3 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Думасының 2017 елның 25 февралендәге 28-13 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 11-11 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 18-30 номерлы, 2025 елның 17 декабрендәге 26-4 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. III бүлектә:

1.1.1. түбәндәге эчтәлекле 3.1.37 пункт өстәргә:

«3.1.37. Казан шәһәре территориясендә элеккеге яшәү урынына кайткан очракта репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан һәм реабилитацияләнгән гражданнарны һәм аларның торак урыннары алу хокукына ия гаилә әгъзаларын торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм әлеге исәпне алып бару»;

1.1.2. 3.1.37 пунктны 3.1.38 пункт дип санарга.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсенә (В.А.Лысачкин) законнарда билгеләнгән тәртиптә әлеге карар нигезендә Нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны, дәүләт тарафыннан теркәлгәннән соң, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**